| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.03.2019 .Алексеевск ш.т.б. № 125

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелгән субсидияләрдән тыш),шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарҗитештерүчеләргә, эш, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында» 2017 елның 18 декабрендәге 459 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Федераль закон таләпләренә туры китерү максатында

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелгән субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товар җитештерүчеләргә, эш, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында» 2017 елның 18 декабрендәге 459 номерлы карарына, яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

- Тәртиптәге 2.1. пунктының 3 пунктчасы «субсидия алучыларның салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнары, җыемнары, иминият кертемнәре, пенялары, штрафлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы (мондый таләп хокукый акт белән каралган очракта) булмаска тиеш»;

- Тәртиптәге 2.1. пунктының 4 пунктчасы «субсидия алучылар – юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булырга тиеш түгел, ә субсидия алучылар – шәхси эшмәкәрләр шәхси эшкуар буларак эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел (мондый таләп хокукый акт белән каралган очракта)»;

- Тәртиптәге 2.1. пунктының 8 пунктчасы
«субсидия алучылар Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетыннан юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә бирелгән

субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары белән расланган товар җитештерүчеләргә, эш, хезмәт күрсәтүче физик затларга субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрнең 3 пунктындагы "б" пунктчасында күрсәтелгән максатка ирешү өчен хокукый акт нигезендә, башка норматив хокукый актлар яки муниципаль хокукый актлар нигезендә субсидия бирү планлаштырылганда акча алырга тиеш түгел»;

- Тәртиптәге3.16. пунктының 10абзацы «субсидияләр биргәндә, аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып, субсидияләр бирү турында шартнамәләргә (килешүләргә) һәм (яисә) норматив хокукый актларга, аларны бирүне җайга сала торган муниципаль хокукый актлар һәм шартнамәләргә (килешүләргә) кертелә торган, әлеге шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән, субсидия алучыларның һәм тәэмин итүчеләрнең (подрядчыларның, башкаручыларның) ризалык бирүе тора, әлеге ризалык товарлар җитештерүгә, эшләр башкаруга, (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләрдән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (склад) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашуы белән, шулай ук мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләрнең устав (склад) капиталларында катнашуы белән коммерциячел оешмалардан тыш) хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә бюджет акчаларын, субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне, баш бүлүче (бүлүче) һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан, тикшерүне гамәлгә ашыруга бәйле булган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә бирелә»;

- Тәртиптәге 4.1 пункт «Субсидия бирә торган бюджет акчаларын баш бүлүче һәм дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органы аларны алучылар тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**